Шәһәр күләмендә Татар халкы һәм Татарстан тарихы фәненнән татар телендә үткәрелә торган олимпиаданың мәктәп этабы биремнәре
2025-2026 нчы уку елы
8 нче сыйныф

Эш вакыты – 90 минут
Гомуми балл – 57

Тәкъдим ителгән җаваплар арасыннан дөресен сайлап алыгыз.

1. 921-922 елларда Болгар дәүләтенә килгән Багдад илчелеге сәркатибе үзе шаһит булган вакыйгаларны, җирле халыкларның көнкүреше турындагы мәгълүматларны теркәгән сәяхәтнамә авторын атагыз. (1 б.)

А) Мөхәммәдьяр Б) Әхмәд ибне Фадлан В) Кол Гали Г) Мәүлә Колый
Җавап: _____

2. Идел буе Болгар дәүләтендә ислам дине кабул ителү белән нинди язу гамәлгә кергән? (1 б.)

А) гарәп язуы Б) латин язуы В) рун язуы
Җавап: _____

3. Чыңгыз хан оныгы, Идел болгарын яулап алучы һәм Алтын Урдага нигез салучы: (1 б.)

А) Үзбәк Б) Мамай В) Батый Г) Җанибәк
Җавап: _____

4. Алтын Урда башкаласы Сарай турында кыйммәтле мәгълүматлар калдырган XIV гасыр гарәп сәяхәтчесенең исеме: (1 б.)

А) Алмыш Б) Ибне Баттута В) Ядегәр Г) Олуг Мөхәммәд
Җавап: _____

5. Алтын Урдада яулап алган җирләрдә ясак җыю һәм халык исәбен алып бару белән шөгыльләнүче җирле идарә башлыгы, хан вәкиле: (1 б.)

А) Бәкләри бәк Б) Калга солтан В) Вассал Г) Баскак
Җавап: _____

6. Казан шәһәренә кайсы елны нигез салынган дип санала? (1 б.)

А) 1552 ел Б) 922 ел В) 1005 ел Г) 1236 ел
Җавап: _____

7. Түбәндә күрсәтелгән ханнардан кем Казан ханлыгы белән идарә итмәгән? (1 б.)
А) Мәхмүд Б) Бирдебәк В) Мөхәммәд Әмин Г) Илһам
Җавап: _____

8. Текстта төшеп калган сүзләрне языгыз. (Һәрбер дөрес җавап өчен 1 б., иң югары – 5 б.)

1. 1236 ел – монгол гаскәрләренең _____ яулап алуы.
2. 1312-1342 еллар – _____ ханның идарә итүе; Алтын Урданың көчле дәүләткә әверелүе.
3. 1549-1551 еллар – Казанда яшь _____ исеменнән _____ идарә итүе.
4. 1758 елда Казанда Беренче _____ гимназиясе ачыла.
5. 1804 ел – _____ ачыла.

9. Күрсәтелгән еллар Казанда булган нинди вакыйгалар белән бәйле? (Һәрбер дөрес җавап өчен 2 б., иң югары – 8 б.)

1. 1708 ел – _____
2. 1718 ел – _____
3. 1774 ел – _____
4. 1799 ел – _____

10. Түбәндә кайсы хөкемдарлар турында сүз барганын дөрес билгеләгез. (Һәрбер дөрес җавап өчен 2 б., иң югары – 12 б.)

1. Монгол империясенә нигез салучы.

Җавап: _____

2. Җүчи Олысы ханы. Исламны Алтын Урданың рәсми дине итүче.

Җавап: _____

3. Төрки каһанлыкка нигез салучы.

Җавап: _____

4. Чыңгызханның оныгы, Көнбатышка яу чабу белән идарә иткән һәм Идел аръягын, Көнчыгыш Европаны яулап алган җиһангир. Җүчи Олысына нигез салучы.

Җавап: _____

5. Европадагы Һуннар дәүләте хөкемдары.

Җавап: _____

6. Болгар хөкемдары. Идел Болгарында ислам динен кабул итү турында Багдад хәлифәлеге белән сөйләшүләр алып баручы.

Җавап: _____

11. Даталарны һәм вакыйгаларны туры китерегез (Һәрбер дөрес җавап өчен 2 б., иң югары – 8 б.)

1)1312-1342 еллар	А) Немец сәяхәтчесе Адам Олеарийның Казанга килүе
2) 1767 ел	Б) Иван Грозныйның Казанга походлары
3) 1636 ел	В) Үзбәк ханның Алтын Урдада хакимлек иткән дәвере
4) 1548, 1549, 1550, 1552 еллар	Г) Патшабикә Екатерина II нең Идел елгасы буенча сәяхәте вакытында Казан шәһәрендә булуы

Җавап:

1	2	3	4

12. Тарихи шәхесләрнең исемнәрен аларның тасвирламалары белән туры китерегез. (Һәрбер дөрес җавап өчен 2 б., иң югары 8 б.).

Тасвирлама	Шәхес
1) Воевода, Казанны алуда катнашкан кенәз	А) Гурий (Руготин Григорий)
2) Дин эшлеклесе, миссионер, Казан епархиясенең беренче архиепископы	Б) Курбский Андрей Михайлович
3) Рус архитекторы, Иван Ширяй белән берлектә, Казан Кремле манараларын һәм диварларын, Благовещение соборын торгызган	В) Карл Фукс
4) Медицина белгече, төбәкне өйрәнүче, Казан университеты профессоры, беренчеләрдән булып Казан татарларының тормыш-көнкүрешен, мәдәниятен өйрәнгән	Г) Иван Постник (Постник Яковлев)

Җавап:

1	2	3	4

13. Текстны игътибар белән укыгыз һәм сорауларга җавап бирегез. (Иң югары 3 б.).

1799 елның кыш урталарында без губерна шәһәре булган Казанга килеп җиттек. […] Миңа 8 яшь иде. Минем әтием һәм Княжевичлар бу кешенең анасын тиз арада […] казна исәбенә укырга бирергә күндерүләрен дәвам иттеләр. Ниһаять, […] миңа формалы мундирлы куртка кидерделәр, постау галстук бәйләделәр, чәчләремне кистеләр, буйга карап бастырдылар […] һәм шунда ук дөрес йөрергә өйрәттеләр. Тау башында торган гимназиянең ачык яшел түбәле һәм гөмбәзле ак зур бинасы хәзер минем күземә күренде һәм мине таң калдырды […].

С.Т. Аксаковның истәлекләрендә нинди уку йорты турында сүз бара? (1 б.). Әлеге уку йорты ничәнче елда оеша? (1 б.)

Җавап: _____

Әлеге оешма нинди уку йорты ачылуына нигез булган? (1 б.)

Җавап:_____

14. Фоторәсемдә Казан төбәгендә туган мәшһүр Россия шагыйре һәм дәүләт эшлеклесе сурәтләнгән. Ул кем? Әлеге шәхеснең тормыш юлы һәм эшчәнлеге турында белгәннәрегезне языгыз. (Иң югары 6 б.).

(Фоторәсемдә кем сурәтләнгән – 1 б.).

(Һәрбер биографик факт өчен – 1 б.).

Җавап:

УҢЫШЛАР ТЕЛИБЕЗ!